| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.03.2021 ел Баулы шәһәре №21

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 20 сентябрендәге 304 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, башкарма хакимиятнең аларның үтәлеше федераль дәүләт транспорт күзәтчелеген, транспорт куркынычсызлыгы өлкәсендә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда чаралар уздырганда бәйләнә торган, шулай ук транспорт чараларын техник карау өлкәсендә мәҗбүри таләпләре булган федераль органнары актларының кайбер актларын һәм аерым нигезләмәләрен гамәлдән чыгару турында,» 2020 елның 26 октябрендәге 1742 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 20 сентябрендәге 304 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нче пунктның 6нчы абзацында «заказ» сүзләрен «сатып алулар» сүзләренә алмаштырырга;

4нче пунктның 5нче абзацында «муниципаль заказ» сүзләрен «сатып алулар» сүзләренә алмаштырырга;

10нчы пунктның 4нче абзацында «муниципаль заказ» сүзләрен «сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

13.2 пунктының 4нче абзацында «Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багаж ташу кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы карарының II бүлеге нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гузаиров